**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел,6 июль № 191

**Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә узгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Болын-Балыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының «Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2016 елның 12 февралендәге 17 номерлы карарының «Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә»нең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1) 8.3 пунктның 6 пунктчасында «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Болын-Балыкчы авыл җирлеге**
**Башлыгы**
**Болын-Балыкчы авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **Р.Х. Гыйльметдинова**